| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Азевского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Азево авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.01.2022 Азево авылы № 16-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлегенең генераль планын әзерләү ихтыяҗы булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге территориясендә җирлек территориясеннән файдалануны үзгәртү күздә тотылмавына, расланган комплекслы социаль-икътисадый үсеш программасы, Татарстан Республикасын һәм Әгерҗе муниципаль районын территориаль планлаштыру схемалары белән федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектлар урнаштыру каралмавына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге **КАРАР ИТТЕ**:

1. 2022 елның «30» декабренә кадәр Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлегенең генераль планын эшләүдә ихтыяҗ булмавын танырга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның «1» гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы порталы составында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе В.С. СЕМЕНОВ